ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 20 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 27 статьяның 5 өлешендә «бер ел эчендә» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Граждан кодексының $173^1$ статьясы кагыйдәләре буенча» сүзләрен өстәргә;

2) 43 статьяга түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Бала тууны рәсмиләштерү кенәгәсендәге баланың атасы турында әлеге Кодексның 42 статьясындагы 2 өлеше нигезендә башкарылган язма шулай ук баланың атасы булып язылган затның варисы таләбе буенча суд тәртибендә дәгъваланырга мөмкин. Күрсәтелгән өлешнең нигезләмәләре бозылган очракта, шул исәптән мондый язма ялган документлар нигезендә йә ата булуы судтан тыш тәртиптә билгеләнгән затның ирекле ихтыяр белдерүеннән башка башкарылган булса, тиешле таләп канәгатьләндерелергә мөмкин.»;

3) 147 статьяның 5 өлешендә «белем бирү оешмасында» сүзләрен «оешмада» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 02 ноябрь
№ 78-ТРЗ